*Мәктәп туры*

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
**ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕ**
(2023-2024 нче уку елы)
**11 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 120 минут**
**Максималь балл – 46**

## I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Тартыкларның чиратлашуы күзәтелгән сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) Гаяз
   ә) агач
   б) тигез
   в) күзлеге

2. Архаизмны билгеләгез. **(2 балл)**
   а) ясак
   ә) мәктәп
   б) мәктүп
   в) чирү

3. Җөмләдәге ясалма сүзнең санын билгеләгез. **(2 балл)**
   *Эшне башлама, башласаң ташлама.* (Мәкаль).
   а) 1
   ә) 2
   б) 3
   в) 4

4. Җөмләдәге фигыльнең төркемчәсен билгеләгез. **(2 балл)**
   *Озын колак алдан ишетер*. (Мәкаль).
   а) сыйфат фигыль
   ә) хәл фигыль
   б) хикәя фигыль
   в) шарт фигыль

5. Кисәкчәне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) дөм
   ә) әмма
   б) вә
   в) бугай

6. Җөмләнең иясен билгеләгез. **(2 балл)**

*Тырышкан тамчы таш тишкән.* (Мәкаль).

а) тырышкан
ә) тамчы
б) таш
в) тишкән

7. Җөмләдәге хәлнең төрен билгеләгез. **(2 балл)**

*Бүре бар дип урманга бармый тормыйлар.* (Мәкаль).

а) сәбәп хәле
ә) максат хәле
б) рәвеш хәле
в) урын хәле

8. Җөмләдәге иярчен компонентның мәгънә ягыннан төрен билгеләгез.**(2 балл)**

*Кем башлаган, шул бетерергә тиеш.* (Мәкаль).

а) иярчен ия җөмлә
ә) иярчен хәбәр җөмлә
б) иярчен шарт җөмлә
в) иярчен рәвеш җөмлә

## II. Теоретик бирем.

Төшеп калган сүзләрне языгыз. **(6 балл)**

Рус-европа телләреннән кергән алынма сүзләрне шул телдәгечә язу – _____________ принцип була. Исемнәрдә күплек сан, иркәләү-кечерәйтү кушымчалары _____________ кушымчалары дип йөртелә. Зат-сан белән төрләнми торган фигыльләр _____________ фигыльләр дип атала. Сүз алдыннан да, сүз артыннан да килә торган кисәкчәләр _____________ языла. Аергыч – исемгә, ә тәмамлык _____________ ияртә. Теркәгечле һәм _____________ тезмә кушма җөмлә була.

## III. Гамәли-иҗади бирем.

1. Текстны татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(12 балл)**

*Дельфины «разговаривают» между собой и очень дружны. Они помогают не только друг другу.*

*Дельфины выносили на берег тонущих моряков.*

*В Австралии дельфин плыл впереди корабля и указывал путь между опасными рифами. А один дельфин каждый день ждал у берега мальчика и перевозил его на спине в школу.*

*Люди решили никогда не охотиться в море на дельфинов.* (Г. Снегирев).

2. “Туган илем сулыклары” дигән темага 12 җөмләдән торган бәйләнешле текст языгыз. **(12 балл)**